**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Кәркәүч авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**11 ноябрь 2024 ел** **№ 5**

**«Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Салтык-Ерыклы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 21 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Салтык-Ерыклы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Салтык-Ерыклы авылы, Тукай урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кәркәүч авыл җирлегенең Салтык-Ерыклы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2024 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш белән капланган юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр);
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (һәйкәлне киртәләү, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, материаллар сатып алу, проект-смета документлары һәм технадзорны гамәлгә ашыру), башкалар су белән тәэмин итүне карап тоту буенча эш төрләре);

- ремонт, коймалар кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту, инвентарь сатып алу, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка төр эшләр);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Салтык-Ерыклы авылы территориясен төзекләндерү, юлларны кардан чистарту, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, башка төр эшләр);

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Кәркәүч авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Кәркәүч авыл
җирлеге башлыгы М.Ф.Зайнутдинов